| АЛЕКСЕЕВСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.07.2026 п.г.т. Алексеевское № 64

**Советның 2022 елның 21 июлендәге 113 номерлы карарының үз көчен югалткан дип тану турында**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында» 2026 елның 30 апрелендәге 783/о номерлы боерыгын исәпкә алып, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставына таянып,

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2022 елның 21 июлендәге 113 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Советының Экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Язынин Р.С.).

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.А. Демидов**